**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 116 17 сентябрь 2018 ел.

Чалпы авыл җирлеге территориясендә
Гражданнарның үзара салымын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чалпы авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чалпы авыл җирлеге башлыгының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 13 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Чалпы авыл җирлеге Советының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 115 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чалпы авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 18 ноябрь 2018 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда карaласы мәсьәлә:
   “Сез, Чалпы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 300 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 һәм 2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   1. авыл эчендәге юлларны ремонтлау:
      1.1 Чалпы авылында Яшьләр урамына, Яна, Бакчалы, Казан, Ленин, Гагарин, Үзәк урамнарына, Балан-Бүләк авылында Ленин, Октябрь урамнарына, Камышлы авылында Яшьләр урамына, Ирекле авылында Гагарин, Яңа, Наратлы урамнарына щебенка жәйдерү;
   2. ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
      2.1. Чалпы авылында зиярат коймасын алыштыру;
      2.2. Чалпы авылында зияратта агачлар кисү;
      2.3. зират мәйданында куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу хезмәте.
   3. җирлектә яшәүчеләрнен ялын оештыру һәм мәдәният оешмаларынын хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:
      3.1. Яна ел бәйрәме, Җиңү көне, Сабантуй, Өлкәннәр көне чаралары оештыру һәм уздыру;

4. җирлектә яшәүчеләргә массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм массакүләм ял итү урыннанрын төзекләндерү:
   4.1. чүп чабу хезмәтенэ түләү;
5. көнкүреш калдыкларын жыюда (шул исәптән аерым җыю) һәм транспорт белән чыгару эшчәнлеген оештыруда катнашу:
   5.1 (көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны жыю, чыгару һәм үтилләштеру);
6. авыл жирлеге территориясен төзеклэндерүне оештыру:
   6.1. Чалпы авылында һәйкәлне профнастил белэн әйләндереп алу, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авылларында һәйкэлләрне агарту, буяу;
   6.2.Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылларында юлларны кардан чистарту.

   "РИЗА" "КАРШЫ"

7. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында - «Маяк» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.М.Мөхәммәтшин